ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОАРЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Школьная ул., дом 30
с.Новый Арыш, 422656

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АРЫШ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп урамы, 30нче йорт,
Яңа Арыш авылы, 422656

Тел.: (8-4361) 25-780, , факс: (8-4361) 25-780, эл.адрес: Nars.Rs.@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 31 нче гыйнвары Яңа Арыш авылы №2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пунктын, 12 статьясындагы 3 пунктын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пункты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә, 2020 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы 6 май 2019 елның №10 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы Зарипов Х.С.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 нче гыйнварындагы 2 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегендә җирләү буенча 2020 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча хезмәт күрсәтү бәясе**

| Хезмәт күрсәтүнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк- яракларны бирү һәм китерү | 2230 |
| 3. Мәетне (гәүдә калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 1020 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү), кремацияләнгән мәет калдыклары | 2874,86 |
| Барлыгы: | 6124,86 |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 нче гыйнварындагы 2 нче номерлы карарына 2 нче номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирләү буенча Яңа Арыш авыл җирлегендә хатыны, якын туганнары, башка туганнары яисә үлгән затның законлы вәкиле булмаганда яисә җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә алган бүтән зат булмаганда күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 485 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яракларны бирү һәм китерү | 1745 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәд калдыкларын) зиратка илтү | 1020 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2874,86 |
| Барлыгы | 6124,86 |